ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                    КАРАР

21.09.2018                    16

с. Набережные Моркваши

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. 1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Моркватшы авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның түбәндәге мәсьәләләре буенча уртак инициативасын чыгарырга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юллау белән килешәсезме:

- Яр буе Морквашы авылында балалар мәйданчыклары төзү;
-Пустые Моркваши бистәсендә балалар мәйданчыгы төзү;
- Десятидворка бистәсендә урамнарны яктыртуны реконструкцияләү;
- Никольский бистәсендәге юлга вак таш җәю;
-Покровка авылында урамнарны яктыртуны реконструкцияләү, контейнер мәйданчыгы төзү;
- Лесные Моркваши авылы зиратына кадәр юлны ремонтларга.

ӘЙЕ                    ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы ____И.Х. Гаязов